# Универсаль уку гамәлләрен формалаштыру

Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандарты белем бирү процессының эчтәлеген яңарту, аның нәтиҗәләрен югары сыйфатлы итү максатын куя һәм шуның нигезендә укытучыларга укучыларда милли кыйммәтләр урнаштыру, белем бирүдә планлаштырылган нәтиҗәләрне һәм универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, бәяләү системасын камилләштерү бурычлары йөкләнә. Укытуда предмет нәтиҗәләрен генә түгел, ә шәхескә караган һәм метапредмет нәтиҗәләрен (универсаль уку гамәлләрен) булдыру буенча эш алып барыла. Белем бирү процессында укучыда универсаль уку гамәлләрен формалаштыра алсак, бала мәктәптә алган белем-күнекмәләрне алдагы тормышта да куллана алачак, үз-үзенә ышанган, мөстәкыйль эш итә торган, коммуникатив, рухи дөньясы бай, кешелекле шәхес буларак тәрбияләнәчәк.

Метапредмет нәтиҗәләре – баланың белем алуга сәләтен һәм алган белемнәрен практикада куллана белү осталыгын булдыра торган универсаль уку гамәлләре комплексы. Универсаль уку гамәлләре – субъектның яңа социаль тәҗрибәне аңлы һәм актив рәвештә үзләштерү юлы белән үзүсешкә һәм үзен камилләштерүгә сәләте, ягъни укучының белем алу процессын оештыра алуы.

Укытучы әзер материални бирүче түгел, ә белем алуны оештыручы булырга, укучыны үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрергә тиеш. Укучылар дәрес темасын үзләре ачарга, уку проблемасын үзләре табарга һәм чишәргә тиеш булалар. Метапредмет нәтиҗәләре укучылар тарафыннан үзләштерелгән регулятив, танып белү, коммуникатив универсаль уку гамәлләрен чагылдыралар.

«Регулятив гамәлләр » – теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала , аның чишелеш юлларын билгели, иң эффектив чишелеш юлын аерып ала, аерып алынган проблеманы мөстәкыйль хәл

итә, рефлексия ясый, үз эшенә адекват бәя бирә һәм әлеге проблема чишелешен тагын да эффектив итү өчен үзенә нәрсә эшләү, нинди юнәлештә камилләшү зарурлыгын ачыклый белү. Регулятив уку гамәлләре укучыларның уку эшчәнлекләрен оештыруын тәэмин итә. Бу гамәлләр укучыларның эшчәнлекләрен планлаштыра белү, үз алдына максат куя белү, нәтиҗә ясау, үз эшчәнлекләрен контрольдә тоту, игътибарлы булу дигәнне аңлата. Регулятив гамәлләр формалашуы – уку мәсьәләсен кую (мин нишләргә тиеш? дип уйлый белү); чишү юлларын билгеләү (ничек эшләп була? болай да, болай да була, тагын башкача эшләп булмыймы икән? дип уйлый белү); эффектив булганын (нәтиҗәгә җиңел илтә торганын, уңаен) сайлап ала алу; куелган мәсьәләне чишү; үз эшенә контроль ясый (нишләргә тиеш идем әле, ничек эшләдем? дип кабат уйлый) белү һәм үз эшенә адекват бәя бирә (ничек булды? куелган максатка ирештемме? ни дәрәҗәдә ирештем? яки яхшымы, начармы? дигән сорауларга җавап бирә) белү .

Регулятив УУГ – ул:

- дәреслек материалы белән эшләү нигезендә укучыларның үз фаразларын әйтә белүне формалаштыру;
- куелган мәсьәләләр белән бәйле рәвештә уку гамәлләрен бәяли белү күнекмәләрен формалаштыру;
- алда көтеләчәк эшне фаразлый (планын төзи) белүне формалаштыру;
- танып белү һәм шәхескә карата рефлексияләрне тормышка ашыра белүне формалаштыру.

Әдәбият дәресләренә таянып регулятив уку гамәлләрен карап китик. Регулятив уку мәсьәләсен кую – укучының уку мәсьәләсен тәгъбир итә алуы. Ул уку материалының эчтәлеге һәм аны тәкъдим итүнең максатын, күнегүләрне эшләү арасында бәйләнеш булдыруны күз алдында тота, “Ни өчен белергә кирәк?” соравына җавап булып тора.

Регулятив планлаштыру – инструкцияләрне үтәү, үрнәк һәм иң гади алгоритм буенча эш итү, уку мәсьәләсен хәл итү өчен гамәлләрнең эзлеклелеген мөстәкыйль рәвештә билгеләү (әдәбият дәресендә әсәрне анализлау белән бәйле рәвештә әсәр анализының барышын планлаштыру). Планлаштыру белән бәйле рәвештә укучыларга типик мәсьәләләр тәкъдим ителә. Алар элементлар (объектлар) арасындагы үзара бәйләнешне, практик мәсьәләне тормышка ашыру вакытында эзлеклелекне билгели. Әдәбият дәресләрендә түбәндәге сорауларга җавап бирүне күздә тота: "Әсәр герое башта һәм аннан соң нәрсәләр эшләде?", "Әсәрнең ахыры яхшы тәмамланыр өчен, геройга нәрсә эшләргә кирәк булачак?" һ.б.

Регулятив фаразлау – укучының үз эшчәнлегенең нәтиҗәсен әйтү, җавапның дөрес вариантын, белемнәрне үзләштерү дәрәҗәсен билгели алуы. Ул булган белемнәрне исәпкә алып нәтиҗәне фаразлауга һәм мөмкин булган кыенлыкларның сәбәпләрен фаразлауга һәм ачыклауга юнәлгән. Бу төркемгә түбәндәге сорауларга җаваплар кирә: ("Син ничек уйлыйсың, ахырда нәрсә булачак?", "Нинди кыенлыклар туачак һәм ни өчен?"). Әдәбият дәресләрендә бу сораулар түбәндәге рәвешне ала: "Әсәр яки вакыйга нәрсә белән тәмамланыр?", "Сюжет барышында нинди борылышлар булачак?" һ.б.

Регулятив контроль һәм үз-үзенә контроль булганда укучы гамәлләр башкаруга эзлекле рәвештә контроль ясый, билгеләнгән үрнәк, кагыйдәләр буенча нәтиҗәгә дә контроль ясый белергә тиеш. Әдәбият дәресендә түбәндәге характердагы биремнәр тәкъдим ителә: "Герой ... дип әйтте. Ул хакмы, шуны тикшер?", "Геройларның кайсысы дөрес әйтте?", "Дәлилли аласыңмы?", "Дәфтәрләрегез белән алышыныгыз, бер-берегезнең эшен тикшерегез", "Сүзлек буенча тикшер..." һ.б.

Регулятив коррекция: укучы эшчәнлеккә кирәкле өстәмәләр һәм үзгәрешләрне кертә, җибәрелгән хаталарны төзәтү буенча укытучының һәм иптәшләренең тәкъдимнәрен адекват рәвештә кабул итә. Коррекция белән

бәйле мәсьәләләр әсәр геройларының гамәлләрендә чагылыш тапкан хаталарны төзәтүдә булышлык итүгә юнәлгән булырга тиеш яки укучыдан текст өстендә эшләгән вакытта вакыйгаларны, күренешләрне дөрес урнаштыру сорала: “Геройга хаталарын төзәтергә булыш”, “Әкиятнең, хикәянең вакыйгаларын дөрес урнаштырырга булыш” һ.б.

Регулятив бәяләү – белемнәрнең, эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгели алу, нәрсә үзләштерелгән, ә нәрсәне әле үзләштерергә тиеш булачагын аңлау, куелган максат белән нәтиҗә арасындагы тәңгәллекне билгеләү. Әдәбият дәресендә түбәндәге биремнәрне үтәүне күздә тота: “Әсәр героеның эш-гамәлләрен бәялә”, “Ә герой үзе үзенең эш-гамәлләрен дөрес бәялиме?” һ.б.

Регулятив үзрегуляция – кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып, гамәлләр кылу, үзенең ихтыярын интеллектуаль пландагы авырлыкларны, физик киртәләрне җиңеп чыгу өчен җыйный белү. Ул танып белү кызыксынуына нигезләнгән типик биремнәрне үз эченә ала.

Универсаль уку гамәлләре бербөтен системаны тәшкил итә, шуңа да аларны комплекслы кулланганда гына көтелгән нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Укучыларда төрле универсаль уку гамәлләрен формалаштырып, планлаштырган нәтиҗәләргә ирешү өстендә эшләү бүгенге дәрес алдына куелган төп таләпләрнең берсе булуын да онытмаска кирәк. Гомумән алганда, федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре белән бәйле рәвештә, дәресләрдә укучыларны уйлату, фикер әйтергә, үз фикерен дәлилләргә өйрәтү, мөстәкыйль эшләргә күнектерү бик мөһим булып санала. Әгәр укучыда универсаль уку гамәлләре формалаштыра алсак, бала мәктәптә алган белем-күнекмәләрне укыту-тәрбия процессында гына түгел, ә реаль тормышта да куллана алачак.

Файдаланылган әдәбият:

1.Гыйльманов Д. Ш. 2014/2015 нче уку елында татар телен укыту үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр.–Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2014. – 52 б.

2. Мөхәмматҗанова А.Х., Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек.– Казан: ТРМҮИ, 2015. – 68б.

3. Мозаффарова. М.Г.«Әдәбият» предметын укыту үзенчәлекләре. Татар әдәбияты буенча башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәткәрләр өчен тәкъдимнәр. – Казан– ТР Мәгарифне үстерү институты, 2014 – 80 бит.

4. Мөхәрләмова Г.Н. Технологик карта: актуальләштерү һәм уку мәсьәләсен кую этаплары. // Мәгариф - 2016. - №7

5. Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф. 2017/2018 нче уку елында татар телен укыту буенча методик тәкъдимнәр – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2017. – 26 б.